ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 өлешендә «капиталь ремонтлау» сүзләреннән соң «, территорияләрне төзекләндерү» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле $19^4$ статья өстәргә:
«$19^4$ статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан чиктәш территорияләр чикләрен билгеләү тәртибе**

1. Чиктәш территорияләрнең чикләре әлеге статьяда билгеләнгән тәртип нигезендә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнә.
2. Чиктәш территорияләрнең чикләре рөхсәт ителгән файдалану төренә, функциональ билгеләнешкә, мәйданга һәм муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрендә билгеләнгән башка факторларга бәйле рәвештә бинадан, төзелмәдән, корылмадан, җир кишәрлеге чикләреннән, әгәр мондый җир кишәрлеге барлыкка китерелгән булса, ара калдыру юлы белән билгеләнә.
Чиктәш территорияләр чикләренең киселеше рөхсәт ителми.

3. Чиктәш территорияләр чикләрендә урнаштырыла алмый торган объектлар һәм территорияләр муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә билгеләнә.

4. Муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрендә чиктәш территорияләр чикләрен билгеләүне һәм үзгәртүне муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан чиктәш территорияләр чикләре схемасын күрсәтелгән кагыйдәләрдә билгеләнә торган таләпләргә туры китерелгән форматлар нигезендә раслау юлы белән гамәлгә ашыру каралган булырга мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 30 ноябрь
№ 92-ТРЗ